| ГЛАВА СТАРОЧУКАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ЧОКАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |
| 18 ноябрь 2021 ел | №11 |

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Уставының 12.1статьясы, Иске Чокалы авыл җирлеге Советының 12.10.2019 ел, № 50/1 карары (15.11.2019 ел, № 52/5 редакциясендә) белән расланган «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе» нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлегенең Иске Чокалы торак пунктында гражданнар җыенын 2021 елның 3 декабренә 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Иске Чокалы авылы, Коминтерна урамы, 18 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча билгеләргә.

2. Гражданнар җыенында түбәндәге мәсьәләне расларга:

"2022 елда Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 650 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме:

- Иске Чокалы авылында Пионер, Коминтерн,1 Май, Тукай урамнарында гамәлдәге юлларга вак таш җәю;

- Иске Чокалы авылында Камил Якуб , Пушкин, Кызыл Армия, Кызыл Йолдыз, Киров, 2 Бишьеллык, Комсомол, урамындагы урам-юл челтәрләрен ремонтлау ;

- Иске Чокалы авылында янгын сүндерү машинасына җылы бокс төзү өчен төзелеш материаллары сатып алу;

- Иске Чокалы авылында урам утларын ремонтлау.

«ӘЙЕ» «ЮК»».

3. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

Иске Чокалы
авыл җирлеге башлыгы: Р.Р.Низамутдинов